МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

№ 1224_ г. Казань № 29.05.2026

Өч яшькә кадәрге балаларны
табиб рецептлары буенча
махсус сөт ризыклары һәм
катнашмалар белән тәэмин итү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын
раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июленнән ФЗ 210-нче номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 елның 31 декабреннән 933-нче номерлы, «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февраленнән 175-нче номерлы карарлары нигезендә б о е р а м:

1. Өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы өч яшькә кадәрге балаларны махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән тәэмин итүдә катнашучы медицина оешмалары җитәкчеләренә өч яшькә кадәрге балаларны махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә әлеге боерык белән расланган административ регламентның үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм

катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 20 июненнән 1447-нче номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерелеп торуын Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Е.В. Демьяновага йөкләргә.

Министр А.Р.Абашев

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән расланган
____29.05.2026_____________ел.
____1224_____________номерлы

Өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Өч яшькә кадәрге балаларны махсус сөт ризыклары һәм табиб рецептлары буенча катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) өч яшькә кадәрге балаларны махсус сөт ризыклары һәм табиб рецептлары буенча катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр-ясалма һәм катнаш тукландыруда торучы, Татарстан Республикасында даими яшәүче, республиканың медицина оешмаларында яшәү урыны буенча амбулатор исәптә торучы өч яшькә кадәрге балаларның ата-анасының (законлы вәкилләренең) берсе:

- «Дарулар әйләнеше турында» 2010 елның 12 апреленнән 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган дарулар һәм даруханә ассортиментындагы башка товарлар сатып алуга түләмен алучылар булып, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артмаган гаиләләрдән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.12.2019 елның 1095 номерлы «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару сатып алуга түләм чаралары турында» (алга таба – социаль күрсәтмәләр). Гаиләдә күрсәтелгән яшьтәге ике һәм аннан күбрәк бала булганда, әлеге хокукка һәр бала ия була;

- 1 нче Кушымта нигезендә хроник авырулар булган өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү, 2009 елның 31 декабреннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 933 номерлы «Өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү тәртибе һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау турында» карары белән расланган (алга таба – хроник авырулар). Гаиләдә күрсәтелгән яшьтәге ике һәм аннан да күбрәк бала булганда, әлеге хокукка һәр бала ия була;

- ВИЧ-инфекцияле аналардан туган, ВИЧ-инфекцияле балалар (МКБ10 коды – R75; B20) (алга таба – медицина күрсәтмәләре). Гаиләдә күрсәтелгән яшьтәге ике һәм аннан күбрәк бала булганда, һәр бала әлеге хокукка ия.

Табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән берничә нигез буенча түләүсез тәэмин итү хокукы булганда, әлеге тәэмин итү бары тик бер нигез буенча гына гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тәкъдим итәргә мөмкин.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры», «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» (https://www.gosuslugi.ru) федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы»нда (https://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – ПГМУ) урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабреннән «Өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 933 номерлы карары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан профильләү юлы белән билгеләнә (әлеге Регламентка 2 нче кушымта).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән тәэмин итү.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның атамасы.

Баланың яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы медицина оешмалары (алга таба – медицина оешмасы).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәге хезмәтләр билгеләнә:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2007 елның 12 февраленнән 110 номерлы «Дару препаратларын, медицина билгеләнешендәге әйберләрне һәм дәвалау туклануының махсуслаштырылган ризыкларын билгеләү һәм язып алу тәртибе турында» (алга таба – рецепт) боерыгы белән расланган 148-1/у-06 номерлы формасы буенча махсус сөт ризыкларына һәм катнашмаларга рецепт;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында Реестр язмасын алып бару каралмаган.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе түбәндәгечә теркәлә:

- рецептлар рецептларны теркәү журналында теркәлә;

- рецепт бирү турындагы язма баланың үсеш тарихына (112/у форма, СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының 1980 елның 4 октябреннән 1030 номерлы боерыгы белән расланган) һәм «Татарстан Республикасы электрон сәламәтлек саклау» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ТР ЭЗ ГИС) пациент картасына кертелә.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу факты теркәлә торган мәгълүмат системасы исеме – ТР ЭЗ ГИС.

2.3.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алу ысуллары:

- участок педиатрында кабул итү вакытында.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыт кысалары.

2.4.1. Участок педиатры тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь вакыт кысалары:

1) мәгълүмат бирү өстәленә (теркәлү өстәленә) мөрәҗәгать итеп:

- 5 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 2 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

- 28 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 3 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

- 3 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 4 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

2) Медицина оешмасының шалтырату үзәгенә телефон аша мөрәҗәгать иткәндә:

- 5 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 2 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

- 28 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 3 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

- 3 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 4 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

3) электрон чират терминалын кулланып:

- 5 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 2 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

- 28 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 3 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

- 3 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 4 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

4) Бердәм портал, ПГМУ, Бердәм Порталның мобиль кушымтасы, ПГМУ ярдәмендә:

- 5 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 2 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

- 28 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 3 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы;

- 3 эш көненнән дә артык узмыйча, гариза бирүче балага карата дәүләт хезмәтен алу өчен участок табиб-педиатрына турыдан-туры мөрәҗәгать иткәннән соң – әлеге регламентның 4 абзацта булган 1.2 пунктына кагылышлы.

2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.6. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыт кысалары.

Медицина оешмасының мәгълүмат стойкасында (регистратурада) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә чиратта көтүнең максималь вакыт кысалары 15 минут тәшкил итә.

Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү турында гариза бирү чиратта көтүне күздә тотмый.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе – нәтиҗә артыннан мөрәҗәгать иткән көнне күрсәтелә.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьен теркәү вакыты.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьен теркәү, шул исәптән электрон рәвештә дә, каралмаган.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайтында (алга таба – Министрлык), шулай ук бердәм порталда, ПГМУда урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы күрсәткечләр.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, шулай ук бердәм порталда, ПГМУда урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алу;

дәүләт хезмәте турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирү турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә мөрәҗәгатьне дә кертеп, күпфункцияле үзәкләр аша гамәлгә ашырылмый.

2.10.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр юк.

2.10.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системалары исемлеге:

- «Татарстан Республикасы электрон сәламәтлек саклау» дәүләт мәгълүмат системасы (ГИС ЭЗ РТ);

- «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ГИС СРН РТ);

- Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы (алга таба – ЕСИА).

2.10.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә алынырга мөмкин:

хезмәт күрсәтү турында медицина оешмасы биналарында урнашкан визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

- «Интернет» челтәре аша:

- Министрлыкның рәсми сайтында;

- ПГМУ аша;

- Бердәм портал аша;

- Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесенең «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчерлык үзәге» рәсми сайтында (алга таба- ДЦ МЗ РТ);

- медицина оешмасының рәсми сайтында.

ПГМУда, бердәм порталда «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләр нигезендә

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыт кысалары турында урнаштырылган мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә түләүсез бирелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыт кысалары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка мөрәҗәгать итүче нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштыру программа тәэминаты хокукына ия кеше тарафыннан түләү алу, мөрәҗәгать итүчене теркәү яки авторизацияләү, яисә аларга шәхси белешмәләр бирү каралган лицензия яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча да керә ала.

2.10.5. Мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып дәүләт хезмәте алуны сорап мөрәҗәгать иткән очракта, ГИС ЭЗ РТ пациент картасы булу һәм әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган документлар турында картада булган белешмәләрнең ПГМУның шәхси кабинетындагы, Бердәм порталдагы белешмәләргә туры килүе зарур.

Хезмәтне ПГМУ аша алу мөмкинлеген тәэмин итү өчен мөрәҗәгать итүче ПГМУда теркәлергә тиеш. ПГМУда авторизация ЕСИА ярдәмендә башкарыла. ЕСИАда теркәлү ысуллары һәм тәртибе турында мәгълүмат ПГМУ сайтында тәкъдим ителгән.

Хезмәтне Бердәм портал аша алу мөмкинлеген тәэмин итү өчен мөрәҗәгать итүче теркәлергә тиеш. Бердәм порталда авторизация ЕСИА ярдәмендә башкарыла. ЕИАДА теркәлү ысуллары һәм тәртибе турында мәгълүмат бердәм порталда бирелгән.

Мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән язылу вакыты чикләрендә кабул итү өчен буш булган теләсә кайсы датага һәм вакытка участок табиб-педиатрына язылу мөмкинлеге бирелә.

Участок табиб-педиатрына язылуны уңышлы башкарганда, мөрәҗәгать итүчегә раслаучы талон бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат, кабул итү датасы, вакыты һәм урыны билгеләнеп, күрсәтелгән адреска җибәрелә.

Кабул итүнең билгеләнгән вакытына кадәр 45 минуттан да соңга калмыйча мөрәҗәгать итүче алдан язылуны гамәлдән чыгарырга хокуклы.

Әгәр мөстәкыйль язылу мөмкинлеге чикләнгән булса, участок табиб-педиатрына язылу медицина оешмасының мәгълүмат стойкасында (регистратурада) мөмкин.

Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче:

а) дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында ПГМУда, Бердәм порталда урнаштырылган мәгълүмат алырга;

б) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы Федераль законының 16 статьясындагы 1 өлешенең $7^2$ пункты нигезендә дәүләт хезмәте алу өчен ПГМУ, Бердәм порталдан файдаланып мөрәҗәгать итәргә.;

в) ПГМУда, Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләргә;

г) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә, кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган ПГМУ, Бердәм портал, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы медицина оешмасының вазыйфаи затларына, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренә, медицина оешмасы хезмәткәрләренең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Дәүләт хезмәтенең аерым этаплары электрон рәвештә күрсәтелә:

дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать итү, шул исәптән, ПГМУ, Бердәм портал, ПГМУ мобиль кушымтасы, Бердәм портал ярдәмендә башкарыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.11.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге шушы Регламентка 3 кушымтада китерелде:

а) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөстәкыйль тапшыра торган документлар;

б) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү өчен үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза телдән йә ПГМУ, Бердәм портал аша унификацияләнгән формаларны кулланып бирелә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар әлеге Регламентның 3 кушымтасының 1 бүлегендә каралган документлар тапшырылмаган очракта кабул ителә.

2.12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору турында карар түбәндәге нигезләрнең берсе булганда кабул ителә:

1) Мәҗбүри медицина иминияте полисы буенча медицина оешмасына беркетү үзгәргән очракта (алга таба – ОМС полисы);

2) ГИС ЭЗ РТ пациент картасындагы белешмәләрнең бала документларына туры килмәве.

2.12.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карар түбәндәге нигезләрнең берсе булганда кабул ителә:

1) бала шушы регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән категорияләргә керми;

2) җан башына уртача керемле яшәү минимумы зурлыгыннан артмаган гаиләләрдән яисә ведомствоара мөрәҗәгатьләр юлы белән алынган, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә алынган белешмәләрнең, гаиләнең җан башына уртача керемле яшәү минимумы күләменнән артмавын раслый торган, тормышның беренче өч яшендәге балаларның Татарстан Республикасында билгеләнгән региональ регистрында бала турында мәгълүматның булмавы.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентка 4 кушымтада китерелгән.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, медицина оешмасы мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару вакыт кысалары

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен (дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) бәяләү үткәрелә торган административ процедураны, аннан соң гамәлгә ашырылуны күздә тоткан административ процедураны гамәлгә ашыру дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәндә, мөрәҗәгать итүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны), мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында 2 һәм аннан да күбрәк тапкыр кабатланырга рөхсәт ителә торган

дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын бүлү каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндәге гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

Участок табиб-педиатры карар кабул итү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

- мөрәҗәгать итүчене профильләштерү (мөрәҗәгать итүчене ПГМУда, бердәм порталда, ПГМУ кушымтасында, бердәм порталда, регистратура мәгълүмат стойкасында, шалтырату үзәгендә идентификацияләү);

- мөрәҗәгать итүчене участок табиб-педиатрына кабул итүгә язылу;

- дәүләт хезмәтен алу хокукын билгеләү турында карар кабул итү:

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек – ГИС ЭЗ РТдан ГИС СРН РТга җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артмаган гаиләләрдән булган өч яшькә кадәрге балаларның төбәк регистрында бала турында мәгълүмат булу-булмавы турында ихтыяҗ;

баланың тикшерү нәтиҗәләрен интерпретацияләү һәм диагноз кую;

- дәүләт хезмәтен күрсәтү йә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү;

- дәүләт хезмәте нәтиҗәсен күрсәтү.

3.3. Дәүләт хезмәте алдан (проактив) режимда күрсәтелми.

## 4. Үзгәреш турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне карау статусы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү гамәлгә ашырыла:

- регистратурада телдән;

- ПГМУ кулланып (дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать иткәндә мәгълүмат автомат рәвештә бирелә);

- Бердәм порталдан файдаланып (мәгълүмат дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать иткәндә автомат рәвештә бирелә);

- медицина оешмасының участок табиб-педиатры кабул итүендә.

Өч яшькә кадәрге балаларны
табиб рецептлары буенча
махсус сөт ризыклары һәм
катнашмалар белән тәэмин итү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (https://www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал);

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – ПГМУ;

«Татарстан Республикасы электрон сәламәтлек саклау» дәүләт мәгълүмат системасы – ГИС ЭЗ РТ;

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы – ГИС СРН РТ;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (https://minzdrav.tatarstan.ru) – Министрлык;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе (https://dcmz.tatarstan.ru) – ДЦ МЗ РТ;

Идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы – ЕСИА;

Мәҗбүри медицина иминияте полисы – ОМС полисы;

Шәхси счетның иминият номеры – СНИЛС;

148-1/у-06 номерлы формасы буенча махсус сөт ризыкларына һәм катнашмаларга рецепт – рецепт;

Медицина оешмасы шалтырату үзәге – медицина оешмасына шалтыратуларны эшкәртү үзәге;

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле – Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат.

Өч яшькә кадәрге балаларны
табиб рецептлары буенча
махсус сөт ризыклары һәм
катнашмалар белән тәэмин итү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билге исеме | Мөрәҗәгать итүченең идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Дару препаратларын, медицина билгеләнешендәге эшләнмәләрне һәм дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктларын билгеләү һәм язып алу тәртибе турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы 2007 елның 12 февраленнән 110 номерлы боерыгы белән расланган 148-1/у-06 номерлы формасы буенча махсус сөт ризыкларына һәм катнашмаларга | «Дарулар әйләнеше турында» 2010 елның 12 апреленнән 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган дарулар һәм даруханә ассортиментының башка товарларын сатып алуга түләмен алучылар булып, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артмаган гаиләләрдән баланың ата-анасының берсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 03.12.2019 елның 1095 номерлы «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга | 1А |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | рецепт | түләү турында»гы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә | |
| 2 | | «Дарулар әйләнеше турында» 2010 елның 12 апреленнән 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган дарулар һәм даруханә ассортиментының башка товарларын сатып алуга түләмен алучылар булып, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артмаган гаиләләрдән баланың законлы вәкиле,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 03.12.2019 елның 1095 номерлы «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында»гы карары белән билгеләнгән | 2А |
| 3 | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.122009 елның 933 нче номерлы «Өч яшькә кадәрге балаларны махсус сөт ризыклары һәм табиб рецептлары буенча катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү тәртибе һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау турында»гы карары белән расланган, өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һәм катнашмалар белән тәэмин итү тәртибенә 1 нче кушымта нигезендә хроник авырулы өч яшькә кадәрге | 3А |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | балаларның ата-анасының берсе | |
| 4 | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.122009 елның 933 нче номерлы «Өч яшькә кадәрге балаларны махсус сөт ризыклары һәм табиб рецептлары буенча катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү тәртибе һәм аны оештыру чыгымнарын финансла турында»гы карары белән расланган, өч яшькә кадәрге балаларны табиб рецептлары буенча махсус сөт ризыклары һә катнашмалар белән тәэмин итү тәртибенә 1 нче кушымта нигезендә хроник авырулы өч яшькә кадәрге балаларның законлы вәкилләренең берсе | 4А |
| 5 | | ВИЧ-инфекцияле анадан туган өч яшькә кадәрге баланың ата-аналарының берсе яки ВИЧ-инфекцияле өч яшькә кадәрге бала (МКБ10 коды – R75; B20) | 5А |
| 6 | | ВИЧ-инфекцияле анадан туган өч яшькә кадәрге баланың законлы вәкиле яки ВИЧ-инфекцияле өч яшькә кадәрге бала (мкб10 коды – R75; B20) | 6А |
| 7 | | Мөрәҗәгать итүченең вәкиле | 7А |

Өч яшькә кадәрге балаларны
табиб рецептлары буенча
махсус сөт ризыклары һәм
катнашмалар белән тәэмин итү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Мөрәҗәгать итүченең идентификаторы | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау | Бирү ысулы | Башка таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | | | | |
| 1. | 1А – 7А | шәхесне таныклаучы документ; | мәгълүмат стойкасына мөрәҗәгать иткәндә (регистратурада) | оригинал |
| | | | Бердәм портал, ПГМУ, Бердәм Порталның мобиль кушымтасы, ПГМУ аша мөрәҗәгать иткәндә | Шәхесне раслый торган документтагы мәгълүматлар дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара эшчәнлеген тәэмин итүче инфраструктурада ЕСИАдагы хисап язмасын раслаганда тикшерелә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | 1А – 7А | Баланың ОМС полисы номеры | мәгълүмат стойкасына мөрәҗәгать иткәндә (регистратурада) |
| | | | медицина оешмасының шалтырату-үзәгенә телефон аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | | электрон чират терминалы ярдәмендә эшләгәндә |
| | | | Бердәм портал, ПГМУ, Бердәм Порталның мобиль кушымтасы, ПГМУ аша мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 1А – 7А | Шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС) | мәгълүмат стойкасына мөрәҗәгать иткәндә (регистратурада) |
| | | | Бердәм портал, ПГМУ, Бердәм Порталның мобиль кушымтасы, ПГМУ аша мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | 2А, 4А, 6А | Мөрәҗәгать итүченең балигъ булмаган бала мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслаучы документлар: | мәгълүмат стойкасына мөрәҗәгать иткәндә (регистратурада) | |
| | | | Бердәм портал, ПГМУ, Бердәм Порталның мобиль кушымтасы, ПГМУ аша мөрәҗәгать иткәндә | |
| 5. | 7А | Ышанычнамә | мәгълүмат стойкасына мөрәҗәгать иткәндә (регистратурада) | |
| 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезен мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тәкъдим ителергә тиеш булганлыктан, гар тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исе | | | | |
| 1. | 1А, 2А, 7А | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 3.12. 2019 елның «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында»гы 1095 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә торган «Дарулар әйләнеше турында»гы 12.04. 2010 елның 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 | мәгълүмат стойкасына мөрәҗәгать иткәндә (регистратурада) | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | статьясындагы 7 өлешендә каралган дару чаралары һәм даруханә ассортиментындагы башка товарлар сатып алуга түләмен алучылар булып Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артмаган гаиләләрдән булган өч яшькә кадәрге балалар турында белешмәләр<br><br>Сорау «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы (ГИС СРН РТ) ярдәмендә Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрелә. | | |

Өч яшькә кадәрге балаларны
табиб рецептлары буенча
махсус сөт ризыклары һәм
катнашмалар белән тәэмин итү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № п/п | Нигезләр исемлеге | Мөрәҗәгать итүченең идентификаторы |
|---|---|---|
| Мөрәҗәгатьне кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге | | |
| 1 | Шушы Регламентка 3 нче кушымтаның 1 нче бүлегендә каралган документларны тапшырмау | 1А – 7А |
| | | |
| Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр исемлеге | | |
| 1 | ОМС полисы буенча медицина оешмасына беркетүне үзгәртү | 1А – 7А |
| 2 | ГИС ЭЗ РТ пациент картасындагы белешмәләрнең бала документларына туры килмәве | 1А – 7А |
| | | |
| Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге | | |
| 1 | Шушы регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән категорияләргә баланың кермәве | 1А – 7А |
| 2 | Җан башына уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрдән яки ведомствоара мөрәҗәгатьләр юлы белән алынган, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, гаиләнең җан башына уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмавын раслаучы белешмәләрнең, тормышның беренче өч яшендәге балаларның Татарстан Республикасында билгеләнгән региональ регистрында бала турында мәгълүматның булмавы | 1А, 2А, 7А |